ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**30.09.2022** № **04-05-182**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2015 нче елның 6 нчы июлендә чыгарылган 09-16-88 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының 2010 нчы елның 1 нче июлендә чыгарылган “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында”гы Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2015 нче елның 6 нчы июлендә чыгарылган 09-16-88 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 23 нче мартында чыгарылган 09-16-42 номерлы, 2018 нче елның 4 нче октябрендә чыгарылган 09-05-161 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясе турындагы Нигезләмәгә, 17.5 пунктын “кызыксынган оешмалар” сүзләреннән соң “Посейдон” ришвәтчелеккә каршы тору өлкәсендә, шул исәптән запрослар җибәрү өчен, дәүләт мәгълүмат системасын кулланырга” сүзләре белән тулыландырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотачакмын.

Рәис Р.Н. Сабиров